БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
20 декабрь 2021 ел

**КАРАР**
№ 96

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольгә кагылышлы өлешендә аерым норматив-хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2021 елның 8 ноябрендәге 79 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәдәге V бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү.

68. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларына яки гамәлләренә (гамәл кылмавына) суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

69. Муниципаль җир контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларына яки гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр шикаять бирү тәртибе кулланылмый.».

2. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2021 елның 8 ноябрендәге 80 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәдәге V бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү.

5.1. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларына яки гамәлләренә (гамәл кылмавына) суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

5.2. Муниципаль торак контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларына яки гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр шикаять бирү тәртибе кулланылмый.».

3. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2021 елның 8 ноябрендәге 81 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы

Балтач муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәдәге 5 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү.

5.1. Автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларына яки гамәлләренә (гамәл кылмавына) суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

5.2. Автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларына яки гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр шикаять бирү тәртибе кулланылмый.».

4. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2021 елның 8 ноябрендәге 82 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә муниципаль урман контроле турында нигезләмәдәге 4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирү.

4.1. Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларына яки гамәлләренә (гамәл кылмавына) суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

4.2. Муниципаль урман контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затларның карарларына яки гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр шикаять бирү тәртибе кулланылмый.».

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе — Р. Р. Нотфуллин